УПРАВЛЕНИЕ ПО НАДЗОРУ ЗА ТЕХНИЧЕСКИМ СОСТОЯНИЕМ САМОХОДНЫХ МАШИН И ДРУГИХ ВИДОВ ТЕХНИКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Федосеевская, 36, г. Казань, 420111

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ҮЗЙӨРЕШЛЕ МАШИНАЛАР ҺӘМ БАШКА ТӨР ТЕХНИКАНЫҢ ТЕХНИК ТОРЫШЫНА КҮЗӘТЧЕЛЕК ИДАРӘСЕ
Федосеев ур., 36, Казан шәһәре, 420111

Телефон, факс (843) 221-77-85, сайт: www.gtn.tatarstan.ru, эл.почта: gostehnadzorrt@mail.ru

ПРИКАЗ БОЕРЫК

03.02.2026 Казан ш. № 01-05/23-пр

Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсенең «Аттракционнарны дәүләт теркәве буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2022 елның 17 июнендәге 01-05/142-пр номерлы боерыгы белән расланган Аттракционнарны дәүләт теркәве буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәреш кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законны үтәү максатында

боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсенең «Аттракционнарны дәүләт теркәве буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2022 елның 17 июнендәге 01-05/142-пр номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсенең 2024 елның 7 июненңзге 01-05/157-пр номерлы боерыгы керткән үзгәрешләре белән) белән расланган Аттракционнарны дәүләт теркәве буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәреш кертеп, аны кушымтада бирелгән яңа редакциядә бәян итәргә.

Җитәкче А.Ш. Борһанов

Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсенең 2022 елның 17 июнендәге 01-05-142-пр номерлы боерыгы белән расланды (Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсенең 03.02.2026 № 01-05/23-пр боерыгы редакциясендә)

## Аттракционнарны дәүләт теркәвенә алу буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты

### 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Аттракционнарны дәүләт теркәвенә алу буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең (алга таба – дәүләт хезмәте) административ регламенты (алга таба – Регламент) дәүләт хезмәте күрсәткәндә Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсе (алга таба – Идарә) административ процедуралары һәм административ гамәлләре стандартын, тәртибен һәм эзлеклелеген билгели.

1.2. Мөрәҗәгать итүчеләр: законлы нигезләрдә аттракционны эксплуатацияләүче һәм күңел ачу хезмәтләрен күрсәтү өчен аттракционнан файдаланучы юридик затлар яки шәхси эшкуар сыйфатында теркәлгән физик затлар (алга таба – мөрәҗәгать итүче).

Мөрәҗәгать итүче исеменнән закон нигезендә яки Россия Федерациясе законнары нигезендә рәсмиләштерелгән ышаныч кәгазе нигезендә эш итүче вәкил дә эш итә ала.

1.3. Дәүләт хезмәте мөрәҗәгать итүчегә мөрәҗәгать итүченең категорияләре (билгеләре) нигезендә күрсәтелергә тиеш, алар «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) федераль реестры» федераль дәүләт мәгълүмат системасында һәм «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасында (алга таба – Бердәм портал) урнаштырыла.

### 2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

2.1. Дәүләт хезмәтенең атамасы

Аттракционнарны дәүләт теркәвенә алу

2.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органның исеме

Татарстан Республикасының Үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсе (алга таба – Идарә).

Дәүләт хезмәтен башкаручы – Идарәнең территориаль бүлекләре (алга таба – Идарә бүлекләре).

### 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе

2.3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булып түбәндәгеләр тора:

1) аттракционны дәүләт теркәвенә алу (теркәүдән баш тарту), дәүләт теркәү тамгасы, дәүләт теркәве турында таныклык (кәгазьдәге документ) бирелә;

2) аттракционның дәүләт теркәвен яңарту (яңартудан баш тарту), дәүләт теркәве турында таныклык (документ кәгазьдә биредә), дәүләт теркәү билгесе бирелә;

3) элек теркәлгән аттракционның булу урыны буенча вакытлыча дәүләт теркәвенә алу (вакытлыча теркәүдән баш тарту), дәүләт теркәве турында таныклык (кәгазь чыганактагы документ) бирелә;

4) аттракционны дәүләт теркәве турында таныклыкның дубликатын бирү, югалган яисә яраксыз хәлгә килгән урынына аттракционга дәүләт теркәү тамгасын бирү (бирүдән баш тарту), дәүләт теркәве турында таныклыкның дубликаты (кәгазь чыганактагы документ) һәм дәүләт теркәү тамгасы бирелә;

5) аттракционга карата кылган теркәү гамәлләре турында белешмә бирү, кылган теркәү гамәлләре турында белешмә бирелә (кәгазь чыганактагы документ яисә көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ);

6) аттракционның дәүләт теркәвен туктату, аттракционның дәүләт теркәвен туктату турында карар бирелә (кәгазь чыганактагы документ яисә көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ).

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе буларак реестр язуын формалаштыру каралмаган.

2.3.2. Хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре Идарә бүлекләрендә, Бердәм портал (техник мөмкинлекләр булганда), Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы (алга таба – Республика порталы) аша алынырга мөмкин.

### 2.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтү вакыты

2.4.1. Гариза бирү ысулларына һәм мөрәҗәгать итүченең хезмәт күрсәтү категорияләренә (билгеләренә) бәйсез рәвештә хезмәт күрсәтүнең максималь срогы:

1) аттракционны дәүләт теркәвенә алганда (теркәүдән баш тартканда) – 18 эш көненнән артык түгел;

2) аттракционның дәүләт теркәвен яңартканда (яңартудан баш тартканда) – 13 эш көненнән дә соңга калмыйча;

3) элек теркәлгән аттракционның булу урыны буенча вакытлыча дәүләт теркәвенә алганда (вакытлыча теркәүдән баш тарту) – 10 эш көненнән артмаска тиеш;

4) аттракционны дәүләт теркәвенә алу турында таныклыкның дубликатын биргәндә, югалган яисә яраксыз хәлгә килгән урынына аттракционга дәүләт теркәү тамгасын биргәндә (бирүдән баш тартканда) – 13 эш көненнән артык түгел;

5) аттракционга карата кылынган теркәү гамәлләре турында белешмә биргәндә – 8 эш көненнән артык түгел;

6) аттракционның дәүләт теркәве туктатылганда – 8 эш көненнән артык түгел.

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документларны бирү мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көндә чират тәртибендә башкарыла.

2.5. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән алына торган түләү күләме һәм аны алу ысуллары

2.5.1. Дәүләт хезмәте түләүле нигездә күрсәтелә.

Дәүләт хезмәте күрсәтүгә дәүләт пошлинасы Россия Федерациясе Салым кодексының 333.33 статьясының 1 пунктындагы 139-143 пунктчаларында билгеләнгән күләмнәрдә алына.

Дәүләт пошлинасының күләме турындагы мәгълүмат Бердәм порталда, Республика порталында һәм Идарә сайтында урнаштырылган.

Дәүләт пошлинасы түбәндәге күләмдә алына:

аттракционны дәүләт теркәвенә алу (дәүләт теркәвен яңарту), шул исәптән аттракционны дәүләт теркәвенә алу турында таныклык һәм аттракционга дәүләт теркәве билгесен биреп, түбәндәгечә түләү алына:

потенциаль биомеханик хәтәрлек дәрәҗәсе югары булганда (RB-1) - 13 000 сум;

потенциаль биомеханик хәтәрлек дәрәҗәсе уртача булганда (RB-2) - 7 000 сум;

потенциаль биомеханик хәтәрлек дәрәҗәсе түбән булганда (RB-3) - 3 500 сум;

элек теркәлгән аттракционның торган урыны буенча вакытлыча дәүләт теркәвенә алу өчен:

потенциаль биомеханик хәтәрлек дәрәҗәсе югары булганда (RB-1) - 2 400 сум;

потенциаль биомеханик хәтәрлек дәрәҗәсе уртача булганда (RB-2) - 1 800 сум;

потенциаль биомеханик хәтәрлек дәрәҗәсе түбән булганда (RB-3) - 1 300 сум;

аттракционны дәүләт теркәвенә алу турында таныклык дубликатын биргән өчен - 600 сум;

аттракционга карата кылынган теркәү гамәлләре турында белешмә биргән өчен - 600 сум;

аттракционга югалган яки яраксызга килгән урынына алмаш итеп дәүләт теркәү билгесен биргән өчен – 1 500 сум.

2.5.2. Дәүләт пошлинасын күчерү өчен кирәкле реквизитлар белән квитанция яисә түләү йөкләмәсе бланкын мөрәҗәгать итүче (аның вәкиле) Идарә бүлегендә яисә Идарә сайтында алырга мөмкин.

Түләнгән дәүләт пошлинасы, дәүләт пошлинасын түләгән затларның юридик яктан әһәмиятле гамәл кылудан баш тарткан очракта, әлеге юридик әһәмияткә ия гамәлне кылган (кыла торган) вәкаләтле органга (вазыйфаи затка) мөрәҗәгать иткәнчегә кадәр кире кайтарылырга тиеш.

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча тапшырылган документка Идарә бүлегенең вазыйфаи затының гаебе белән җибәрелгән хаталарны төзәтүгә юнәлдерелгән үзгәрешләр кертелгән очракта, мөрәҗәгать итүчедән түләү алынмый.

2.6. Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы рәсми мөрәҗәгатьне тапшырганда яисә мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәләрен алганда чират көтүнең максималь вакыты

2.6.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кәгазь чыганакта гариза тапшырганда иң күп көтү вакыты – 15 минуттан артык түгел.

Дәүләт хезмәтенең нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь вакыты 15 минуттан артырга тиеш түгел.

2.6.2. Мөрәҗәгать итүчеләрнең аерым категорияләре өчен чират билгеләнмәгән.

2.7. Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтү турында мөрәҗәгатен теркәү чоры

Гариза алынган көннән соң бер көн эчендә теркәлә.

Республика порталына электрон рәвештә кергән гариза кергән көнендә теркәлә.

Ял (бәйрәм) көнендә, эшләми торган вакытта электрон формада кергән гариза икенче эш көненә теркәлә.

2.8 Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарга карата таләпләр

2.8.1. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарга карата таләпләр турында белешмәләр Идарәнең рәсми сайтында, Бердәм порталда (техник мөмкинлекләр булганда) һәм Республика порталында урнаштырыла.

2.9. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең мөмкинлекле һәм сыйфатлы булу күрсәткечләре

2.9.1. Дәүләт хезмәтеннән файдалану һәм сыйфат күрсәткечләре Идарәнең рәсми сайтында, Бердәм порталда (техник мөмкинлекләр булганда) һәм Республика порталында урнаштырыла.

2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтүгә башка таләпләр, шул исәптән: күпфункцияле үзәкләрдә дәүләт хезмәте күрсәтүнең үзенчәлекләрен һәм электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә ала торган; Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә дәүләт хезмәте турында белешмәләр бирү турында

2.10.1. «Татарстан Республикасында дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге» дәүләт бюджет учреждениесендә дәүләт хезмәте күрсәтү гамәлгә ашырылмый.

2.10.2. Электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләре:

1) электрон формада дәүләт хезмәте күрсәткәндә мөрәҗәгать итүче хокуклы:

дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында Республика порталында урнаштырылган мәгълүматны алырга;

дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка документлар Республика порталы ярдәмендә тапшырырга;

электрон формада тапшырылган дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаларны үтәү барышы турында белешмәләр алырга;

дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфатына бәя бирергә;

дәүләт хезмәтләрен күрсәтүче органнар, аларның вазыйфаи затлары, дәүләт

хезмәткәрләре тарафыннан дәүләт хезмәтләрен күрсәткәндә кылынган карарларга һәм гамәлләргә (гамәл кылмауларга) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү процессын тәэмин итә торган Республика порталы аша Идарә бүлекләре хезмәткәрләре карарына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаять бирергә;

2) гаризаны формалаштыру, гаризаны өстәмә рәвештә нинди дә булса башка формада тапшыру зарурлыгыннан тыш, Республика порталында гаризаның электрон формасын тутыру юлы белән гамәлгә ашырыла;

3) гаризаны формалаштырганда:

хезмәт күрсәтү өчен кирәкле гаризаның һәм башка документларның күчермәләрен алу һәм саклап кую;

гаризаның электрон формасы күчермәсен кәгазьдә бастырып чыгару;

файдаланучы ихтыярына карап, шул исәптән гаризаның электрон формасына ялгыш керткәндә һәм күрсәткечләрне яңадан кертү зарурлыгы булганда да, теләсә кайсы вакытта электрон гариза формасына элегрәк кертелгән күрсәткечләрне саклау;

элегрәк кертелгән мәгълүматларны югалтмыйча, электрон гариза формасын тутыруның теләсә кайсы этапларына яңадан әйләнеп кайту;

кимендә бер ел дәвамында элегрәк тапшырылган гаризаларны мөрәҗәгать итүче тарафыннан карау мөмкинлеге, шулай ук өлешчә формалаштырылган гаризалар буенча – кимендә өч ай дәвамында.

Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми.

Дәүләт хезмәте күрсәткәндә кулланыла:

1) «Ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы;

2) Республика порталы;

3) дәүләт һәм муниципаль түләүләр турында дәүләт мәгълүмат системасы (ГИС ГМП);

4) «Гостехнадзор Эксперт» автоматлаштырылган мәгълүмат системасы.

Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында мәгълүмат Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә урнаштырыла.

2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы исемлеге

2.11.1. Регламентның 3 нче кушымтасы таблицасында дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы исемлеге китерелгән, түбәндәгечә бүленешләр белән:

1) мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен мөстәкыйль тапшырырга тиешле документлар;

2) мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен мөстәкыйль тапшырырга хокуклы документлар, чөнки алар ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында тапшырылырга тиеш.

Гаризаның формасы Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Аттракционнарны дәүләт теркәвенә алу кагыйдәләрен раслау турында» 2019 елның 30 декабрендәге 1939 номерлы карары белән расланган.

Гариза формалары һәм хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документлар турында белешмәләр Регламентның 3 нче һәм 5 нче кушымталарында китерелгән.

Дәүләт хезмәте күрсәтүдән файдалану өчен гариза бланкын мөрәҗәгать итүче Идарәгә һәм Идарә бүлекләренә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Бланкның электрон рәвеше Идарәнең рәсми сайтында урнаштырылган.

2.12. Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаны һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге һәм дәүләт хезмәтен күрсәтүне туктатып тору яисә баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге

2.12.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризаны һәм документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр булып түбәндәгеләр тора:

1) гаризаның (рәсми мөрәҗәгатьнең) һәм электрон формадагы башка документларның законнарны бозып, электрон имзадан файдаланып имзаланган булуы;

2) электрон документларның аларның форматларына карата таләпләргә туры килмәве һәм (яки) укылмавы;

3) мөрәҗәгать итүче булмаган затның мөрәҗәгать итүе.

2.12.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору нигезләре каралмаган.

2.12.3. Дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту нигезләре:

1) Кагыйдәләр нигезендә дәүләт теркәвенә алынырга тиешле булмаган аттракционны дәүләт теркәвенә алу турында гариза белән мөрәҗәгать итү;

2) Кагыйдәләр нигезендә мәҗбүри булырга тиешле документлар яки белешмәләр булмау;

3) тапшырылган документларның норматив хокукый актларда яисә норматив-техник документларда билгеләнгән таләпләргә туры килмәве;

4) гамәлдә булу вакыты чыккан документлар тапшыру;

5) тапшырылган документларның гамәлдән чыгуы турында белешмәләр булу;

6) тапшырылган (алынган) документларда (белешмәләрдә) каршылыклы яисә дөрес булмаган мәгълүмат булу;

7) вәкаләтле дәүләт органының аттракционга карата юридик яктан әһәмиятле гамәлләр кылуны туктатып тору (тыю) турында карары булу;

8) караган вакытта фактик билгеләнгән белешмәләрнең тапшырылган (алынган) документларга (белешмәләргә) туры килмәве;

9) автоматлаштырылган «Гостехнадзор Эксперт» мәгълүмат системасында аттракционны дәүләт теркәвенә алу турында гамәле бетмәгән белешмәләр булу (аттракционны дәүләт теркәвенә алу турында гариза белән мөрәҗәгать иткәндә);

10) автоматлаштырылган «Гостехнадзор Эксперт» мәгълүмат системасында аттракционны дәүләт теркәвенә алу турында гамәле бетмәгән белешмәләр булмау (аттракционны дәүләт теркәвенә алу турында гариза белән мөрәҗәгать итүдән тыш);

11) автоматлаштырылган «Гостехнадзор Эксперт» мәгълүмат системасында аттракционны түбәндәге нигезләр буенча дәүләт теркәвенә алуны туктату турында белешмәләрнең булуы:

- аттракционны дәүләт теркәвенә алуны туктату турында суд карары үз көченә кергән;

- аттракционның дәүләт теркәве туктатылганнан соң 12 ай вакыт узган, һәм аттракционны дәүләт теркәвенә алу яңартылмаган;

- мөрәҗәгать итүче тарафыннан аттракционны дәүләт теркәвенә алуны туктату турында гариза бирелгән;

12) аттракционның "Аттракционнарның куркынычсызлыгы турында" Евразия икътисадый берлеге Техник регламенты (2018 елның 18 апреленнән беренче тапкыр файдалануга тапшырылган аттракционнарга карата) таләпләренә яисә Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән таләпләргә туры килмәве (2018 елның 18 апреленә кадәр беренче тапкыр файдалануга тапшырылган аттракционнарга карата).

2.12.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарткан очракта, Идарә мөрәҗәгать итүчегә мондый баш тартуның сәбәпләре турында, кире кагуга сәбәп булган документлар һәм мәгълүмат исемлеген күрсәтеп, шулай ук федераль законнарда һәм (яисә) башка норматив хокукый актларда билгеләнгән дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартуга китергән таләпләр исемлеген күрсәтеп, хәбәр итә.

2.12.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаны һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге, шулай ук мөрәҗәгать итүченең категорияләрен (билгеләрен) исәпкә алып, дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге әлеге Регламентка 4 нче кушымтада китерелгән.

3. Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм үтәлү сроклары.

3.1. Административ процедуралар исемлеге

3.1.1. Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә гамәлгә ашырыла торган административ процедуралар исемлеге:

мөрәҗәгать итүчене профильләштерү;

дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле гаризаны, документларны һәм (яисә) мәгълүматны кабул итү;

ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек;

мөрәҗәгать итүче һәм (яисә) мөрәҗәгать итүченең объектлары һәм (яисә) башка объектлар турында белешмәләрне, шулай ук мөрәҗәгать итүче белемнәренең (күнекмәләренең) Россия Федерациясе законнары таләпләренә туры килү-килмәвен бәяләү (дәүләт хезмәтен күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту) турында карар кабул итү процедурасы кысаларында тикшерелә торган таләпләрдән тыш) (алга таба – бәяләү процедурасы);

дәүләт хезмәте күрсәтү турында (күрсәтүдән баш тарту турында) карар кабул итү;

дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү.

3.1.2. Дәүләт хезмәтен алгарышлы (проактив) режимда күрсәтү гамәлгә ашырылмый.

3.2. Мөрәҗәгать итүчене профильләштерү

Мөрәҗәгать итүчене профильләштерү мөрәҗәгать итүченең категорияләре (билгеләре) күрсәтелгән гариза аша дәүләт хезмәтен күрсәтүче орган тарафыннан үткәрелә торган мөрәҗәгать итүченең категориясен (билгеләрен) билгеләү максатларында мөрәҗәгать итүчегә анкета бирүдән гыйбарәт. Мөрәҗәгать итүче тутырган гариза нәтиҗәләре буенча мөрәҗәгать итүче билгеләре күрсәткечләренең

тулы исемлеге билгеләнә, аларның һәркайсы мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен тапшырырга тиешле документларның билгеле бер исемлегенә туры килә.

Мөрәҗәгать итүчеләрнең категорияләре (билгеләре) идентификаторлары Регламентның 2 нче кушымтасында китерелгән.

3.3. Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле гаризаны һәм документларны һәм (яисә) мәгълүматны кабул итү.

3.3.1. Мөрәҗәгать итүченең категориясе (билгеләре) нигезендә дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документлар һәм (яисә) мәгълүмат исемлеге, шулай ук күрсәтелгән документларны һәм (яисә) мәгълүматны бирү ысуллары Регламентның 2 нче кушымтасында китерелгән.

3.3.2. Мөрәҗәгать итүчеләр белән аралашканда мөрәҗәгать итүченең шәхесен билгеләү (идентификацияләү) ысуллары булып түбәндәгеләр тора:

а) Идарәдә, Идарә бүлекләрендә – мөрәҗәгать итүченең шәхесен таныклаучы документы;

б) Республика порталы ярдәмендә – Бердәм идентификация һәм аутентификация системасы, шулай ук көчәйтелгән квалификацияле электрон имза, тикшерү ачкычы сертификаты Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә электрон рәвештә дәүләт хезмәтләрен күрсәтү өчен файдаланыла торган мәгълүмати системаларның мәгълүмати-технологик үзара хезмәттәшлеген тәэмин итә торган инфраструктурада булдырылган һәм кулланыла торган көчәйтелгән квалификациясез электрон имза.

3.3.3. Гаризаны, документларны һәм (яисә) мәгълүматны кабул итүдән баш тарту турында карар кабул итү өчен нигезләр, ә мондый нигезләр булмаган очракта – аларның булмавын күрсәтү Регламентның 4 нче кушымтасында китерелгән.

3.3.4. Гаризаны һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны теркәү вакыты – гариза кергән вакыттан алып бер көн эчендә.

3.3.5. Экстерриториаль принцип буенча дәүләт хезмәте күрсәтү каралмаган.

3.4. Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек

Ведомствоара гарызнамәләр формалаштыру һәм дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы органнарга җибәрү.

Мөрәҗәгать итүченең теркәлгән гаризасы рәсми мөрәҗәгать җибәрү өчен нигез булып тора.

Идарә бүлегенең баш дәүләт инженер-инспекторы (шул исәптән ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасыннан файдаланып) түбәндәгеләрне бирү турында гаризалар юллый:

Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан яисә Шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә (Татарстан Республикасы буенча Федераль салым хезмәте идарәсенә);

аттракционны кадастр исәбенә кую турында белешмәләр (аттракцион капиталь төзелеш объекты булган очракта);

транспорт чарасын дәүләт теркәвенә алу һәм аларга техник карау узу турында белешмәләр (аттракцион транспорт чарасына монтажланган очракта);

дәүләт пошлинасын түләү турында мәгълүмат (Татарстан Республикасы Федераль казначылык идарәсенә);

төбәк мәгълүмат системасыннан – аттракцион турында мәгълүматлар.

Әлеге органнарга ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү максатында җибәрелә.

Регламентның әлеге пунктчасында билгеләнә торган процедуралар гариза һәм документларны теркәү көнендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: белешмәләр бирү турында җибәрелгән рәсми мөрәҗәгатьләр.

Белешмәләр белән тәэмин итүче белгечләр ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша килгән мөрәҗәгатьләр нигезендә сорала торган документларны (мәгълүматларны) бирә яисә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документның һәм (яисә) мәгълүматларның булмавы турында белдерү җибәрә.

Документлар (аларның күчермәләре, аларда булган белешмәләр) ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр буенча әлеге документлар белән эш итүче органнар тарафыннан электрон формада, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәткәндә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек итү кагыйдәләрен, шул исәптән Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте башкарма органнары һәм (яисә) җирле үзидарә органнары арасында ведомствоара мәгълүмат хезмәттәшлекне оештыруның киңәш ителә торган кагыйдәләрен раслау һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларын һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» 2021 елның 23 июнендәге 963 номерлы карары нигезендә ведомствоара гаризаны юллаган вакыттан башлап 48 сәгатьтән артып китмәгән чорда бирелә.

Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кәгазь чыганакта башкарылырга мөмкин:

1) сорала торган белешмәләр электрон формада булмауга бәйле рәвештә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлекне электрон формада гамәлгә ашырып булмаган очракта;

2) ведомствоара рәсми мөрәҗәгать җибәргәндә, кәгазь чыганакта документларның оригиналларын тапшырырга кирәк булганда.

Әгәр ведомствоара хезмәттәшлек кәгазь чыганакта гамәлгә ашырылса, документлар (аларның күчермәләре яки аларда булган белешмәләр) әлеге документлар алар карамагында булган органнар тарафыннан бирелә.

210-ФЗ номерлы федераль законның $7^2$ статьясындагы 3 өлеше нигезендә ведомствоара гарызнамәләргә җаваплар әзерләү һәм җибәрү срогы ведомствоара гарызнамә алынган көннән башлап биш эш көненнән (ике эш көне - дәүләт кадастр исәбен һәм (яисә) күчемсез мөлкәт объектларына хокукларны дәүләт теркәвенә алганда) артмаска тиеш.

Процедураның нәтиҗәсе булып сорала торган документларны (аларның күчермәләрен яки андагы белешмәләрне) алу яисә ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләрне җибәрү өчен җаваплы вазыйфаи затка җибәрелгән баш тарту турында белдерүләр тора.

Белешмәләрне куллануның максатлары булып мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылган документларның дөреслеген билгеләү, шулай ук законнарны һәм мөрәҗәгать итүченең хокукларын бозу очракларын булдырмый торган карарлар кабул итү тора.

### 3.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында (күрсәтүдән баш тарту турында) карар кабул итү

3.5.1. Дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр Регламентның 4 нче кушымтасында китерелгән. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында (күрсәтүдән баш тарту турында) карар кабул итү Идарә һәм Идарә бүлекләре карар кабул итү өчен кирәкле барлык белешмәләрне алган көннән алып 1 эш көненнән дә артмаган вакытта гамәлгә ашырыла.

### 3.6. Мөрәҗәгать итүче һәм (яисә) мөрәҗәгать итүченең объектлары һәм (яисә) башка объектлар турында белешмәләрне, шулай ук мөрәҗәгать итүче белемнәренең (күнекмәләренең) Россия Федерациясе законнары таләпләренә туры килү-килмәвен бәяләү (дәүләт хезмәтен күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту) турында карар кабул итү процедурасы кысаларында тикшерелә торган таләпләрдән тыш)

3.6.1. Дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен мөрәҗәгать итүче турындагы белешмәләрне (гаризаны һәм аңа беркетелә торган документларны һәм белешмәләрне карау) һәм мөрәҗәгать итүченең Россия Федерациясе законнары таләпләренә туры килү-килмәү мәсьәләсенә караган объектларны объектны карап чыгу юлы белән (мөрәҗәгать итүче яисә аның вәкиле катнашында) бәяләү процедурасын үткәрү кирәк.

3.6.2. Бәяләү процедурасы аттракционны дәүләт теркәвенә алганда, аттракционны дәүләт теркәвенә алуны яңартканда һәм элек теркәлгән аттракционның булу урыны буенча вакытлыча дәүләт теркәвенә алганда үткәрелә.

3.6.3. Аттракционны караганда аттракцион визуаль алым белән тәңгәлләштерелә, аттракционның маркировкасы һәм аның тапшырылган документларына туры килүе һәм түбәндәгеләрнең булу-булмавы тикшерелә:

1) аттракционга керү юлында килүчеләр өчен урнаштырылган аттракционнан файдалану кагыйдәләре, шулай ук инвалид пассажирларга хезмәт күрсәтү кагыйдәләре, әгәр аттракционның биомеханик йогынтысы алар өчен ярарлык булмаса, сәламәтлек торышы буенча, яшькә, буй озынлыгына һәм тән авырлыгына бәйле рәвештә аттракционнан файдаланудагы чикләмәләр турында мәгълүмат (әгәр дә бу аттракционны эшләтү документларында каралган булса), тикшерү үткәргән оешма күрсәтелгән соңгы еллык тикшерү датасы турында мәгълүмат һәм алдагы еллык тикшерүнең датасы турында күрсәтелгән мәгълүмат тактасы;

2) пассажирларның буй озынлыгын һәм тән авырлыгын үлчәү чаралары (әгәр эксплуатация документларында аттракционнан файдалану өчен буй озынлыгы һәм тән авырлыгы буенча чикләүләр каралган булса);

3) аттракцион пульты янында урнаштырылган, аттракционның төп техник сыйфатламалары турындагы белешмәләрне үз эченә алган табличкалар;

4) пассажирлар белән аттракционны йөкләү схемалары (әгәр бу эксплуатация документларында каралган булса);

5) эш урынында урнаштырылган, хезмәт күрсәтүче персоналга карата, чиктән тыш куркыныч компонентларга һәм чиктән тыш куркыныч параметрларга карата көндәлек тикшерүләр тәртибенә карата таләпләрне, аттракционга хезмәт күрсәтү буенча төп кагыйдәләргә кагылышлы табличкалар;

6) медицина аптечкалары;

7) урнаштырылырга тиешле эвакуация билгеләре;

8) зур биеклектән яки җиргә карата шактый авыш креслолардан пассажирларны эвакуацияләү буенча чаралар турында план һәм мәгълүмат (эксплуатация документлары нигезендә);

9) пассажирларны пассажир модульләреннән эвакуацияләү чаралары (әгәр бу эксплуатация документларында каралган булса);

10) аттракцион эше вакытында һәм ул эшләмәгән вакытта килгән кунакларның куркыныч зоналарга (пассажирлар модульләре, механизмнар хәрәкәте зоналары, электр җиһазлары белән шкафлар, платформа һәм хезмәт күрсәтүче персонал өчен баскычлар) ирекле үтеп керүен булдырмый торган эксплуатация документларында каралган коймалар һәм башка чаралар;

11) аттракцион мәйданында җил көчен һәм әйләнә-тирә һава температурасын үлчәү өчен билгеләнгән приборлар (эксплуатация документларында җил яки температурага карап, аттракционны куллану буенча чикләүләр каралган булса);

12) аттракционны эшләтү, шулай ук техник хезмәт күрсәтү һәм ремонтлау таләпләрен үтәүне тәэмин итә торган журналларның оригиналлары, мөрәҗәгать итүче тарафыннан таныкланган күчермәләре (элек файдаланууда булган аттракционнар өчен – гариза бирелгән көнгә кадәр кимендә 12 ай өчен, әгәр аттракцион 12 айдан кимрәк файдаланылган булса – аттракционны эшләтү чоры өчен).

Аттракционны караганда, видеофиксация (мөрәҗәгать итүче катнашында) үткәрү юлы белән, аны сынап эшләтеп карыйлар.

Бәяләү процедурасының дәвамлылыгы аттракционны дәүләт теркәвенә алудан баш тарту өчен нигезләр булмау турында карар кабул ителгән көннән алып 5 эш көне тәшкил итә.

Идарәне, Идарә бүлекләрен бәяләү процедурасын үткәрүче субъект.

Бәяләү процедурасы объекты – гариза һәм аңа беркетелә торган, мөрәҗәгать итүче тапшырган белешмәләрнең дөреслеген раслаучы документлар, ә бәяләү предметы булып аттракционның Теркәү кагыйдәләренә туры килүен билгеләү тора.

Мәҗбүри таләпләр үтәлешен урынга чыгып бәяләү нәтиҗәләре буенча карау акты рәсмиләштерелә һәм аттракционны дәүләт теркәвенә алу турында яисә баш тарту турында язмача карар кабул ителә.

### 3.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү

3.7.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү түбәндәгеләрдән артмаган срокта гамәлгә ашырыла:

